КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 октябрь г.Казань № 1327

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 май, 367 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы турындагы нигезләмәсен һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы составын раслау турында» 2021 ел, 24 май, 367 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 октябрь, 1110 нчы; 2023 ел, 27 апрель, 535 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы составына (алга таба – совет) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

совет составыннан А.Г.Карсаловны, В.П.Пятыхны, Р.Р.Гыйсмәтовны чыгарырга;

совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Азат Әнәс улы Нурмөхәммәтовны (килешү буенча);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Төбәкләрне үстерү департаменты директоры урынбасары Александр Андреевич Солдатовны (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин